Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең Надеждино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

18 октябрь, 2024 ел № 4

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлегенең Надеждино торак пункты гражданнарының 2024 елның 18 октябрендәге җыены беркетмәсе нигезендә түбәндәгеләр ачыкланды:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 173 (йөз җитмеш өч).

- халык җыены эшендә катнашкан гражданнарның гомуми саны 89 (сиксән тугыз).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 89 (унсиксән тугыз).

- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 0 (ноль).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2025 елда Надеждино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлар, эшләмәүче 2 төркем инвалидлар сугышчан хәрәкәтләрдә катнашучылар, биш һәм аннан да күбрәк баласы булган күпбалалы гаиләләр, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Яшьләр ур., Яңа ур., Космонавтлар ур.)» **кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов